Personalia

# ON THE JUBILEE OF THE PROMINENT HISTORIAN NADIR DAVLET

**Iskander Ayazovich Gilyazov,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str, Kazan, 420008, Russia,
gilyzov1958@gmail.com.



**DAVLET NADIR** (1944) is a historian, PhD (1985), and Professor (1990). In 1963-1967, he worked for the Islamic Encyclopedia Institution and from 1967 to 1971 he was a researcher at the Institute of Turkish Culture in Ankara, Turkey. In 1972-1984 Davlet Nadir worked for the radio station “Freedom” in Munich, Germany. Simultaneously, in 1970-1980, he was an editor-in-chief and one of the editors of the Turkish journal “Kazan”. Since 1984 he has been a lecturer, and more recently

**ДӘҮЛӘТ НАДИР** (1944) − тарихчы, тарих фәннәре докторы (1985), профессор (1990). 1963-1967 елларда Төркиянең Анкара шәһәрендә Ислам энциклопедиясе, 1967-1971 елларда Төрек мәдәнияте фәнни-тикшеренү институты хезмәткәре. 1972-1984 елларда Мюнхенда (ГФР) «Азатлык» радиостанциясендә эшли. Бер үк вакытта 1970-1980 елларда Төркиядә нәшер ителгән «Казан» журналының баш мөхәррире һәм

**ДАВЛЕТ НАДИР** (1944) − историк, доктор исторических наук (1985), профессор (1990). В 1963-1967 гг. сотрудник Исламской энциклопедии, в 1967-1971 гг. сотрудник НИИ тюркской культуры в Анкаре (Турция). В 1972-1984 гг. работает на радиостанции «Свобода» в Мюнхене (ФРГ). Одновременно в 1970-1980 гг. главный редактор и редактор издававшегося в Турции журнала «Казан». С 1984 года преподаватель, затем профессор Мармар-

he has been a professor of Marmara University in Istanbul.

His works are devoted to the history of the Turkic peoples and international relations. His numerous articles and 20 monographs, including 4 books in the Tatar language were published in different languages.

мөхәррире. 1984 елдан Истанбулда Мәрмәрә университетында укыта, профессор.

Хезмәтләре төрки халыклар тарихына һәм халыкара мөнәсәбәтләргә карый. Төрле телләрдә күпсанлы мәкаләләре, 20 монографиясе нәшер ителгән, шулар арасында татар телендә 4 монографиясе бар.

ского университета в Стамбуле (Турция).

Труды по истории тюркских народов и международным отношениям. На разных языках изданы многочисленные статьи, 20 монографий, среди которых 4 монографии на татарском языке.

I first heard the name Nadir Davlet at the beginning of 1980. When I was working at the Institute of Language, Literature and History named after G. Ibrahimov, Prof. Alfred Khalikov delivered a lecture for young scientists on Tatar scientists in other countries. It was an unforgettable experience; I listened to the lecture with bated breath, astonished, as I knew nothing about the lives and work of such authoritative and prominent representatives of the Tatar intelligentsia living in other countries. Since then, I have been interested in studying the fate of the Tatar emigration; one of the areas of my scientific research relates to Tartars living in other countries. Since then, I have felt sincere respect for Nadir Davlet, taking off my hat to him and his great scientific research.

Nadir Davlet is a unique person with an amazing and highly distinctive destiny. What accounts for his originality and uniqueness?

Firstly, it is, no doubt, Nadir Davlet's life story. His sophisticated, zigzag, tragic, and at the same time happy destiny reminds me of the fate of our nation. On the one hand, the scholar's family suffered, was banished from their home and native land, and he had to leave his country. On the other hand, he was able to maintain his inner strength, power, pride and his belonging to the Tatar nation in those difficult times.

Nadir Davlet was born on the 15 July, 1944 in the city of Mukden in the Far East. He suffered much hardship in early childhood: he was separated from his parents at a very early age and was brought up by other people. Ultimately, the fate brought him to Turkey, where, in 1967-1971, he studied at Istanbul University. Later, in 1972-1974, he continued his studies at Munich Ludwig Maximilian University in Germany. After returning to Turkey, Nadir Davlet devoted his whole soul to the study of historical issues. For many years, the researcher worked at Marmara University, where he was a leading expert at the Center for the Historical and Cultural Studies of the Turkic peoples.

At the same time, it is important to note that Nadir Davlet made considerable contributions to raising national awareness and promoting Tatar culture to our nation's people, who lived in Turkey in the years 1960-1970. For example, the youth club named after Tukai "Tukai's Bulletin", which later, at the end of the 1960s changed its name to the "Mutual Assistance of Volga-Ural Turkic Tatars Society", was organized owing to the activity and assertiveness of Nadir Davlet. Undoubtedly, these great results were achieved due to selfless work of Tatars who emigrated from China to Turkey, with Nadir Davlet among them. It is appropriate to remember the journal "Kazan", published by the noble entrepreneur and philanthropist Akhmad Vali Mangar. Having been published for ten years, this journal still attracts our attention owing to its phenomenally rich content. It described the fate of the Tatars living in other countries, especially in Turkey. In my opinion, the journal "Kazan" is an authoritative edition published by the Tatars in foreign countries after the war. No doubt, we can put it on a par with the "New National Road" produced by Gayaz Ishaki, which was issued in Germany before the war. It is important to note that in 1970-1973, Nadir Davlet was editor-in-chief of the journal, and in 1973-1980 he was a member of the editorial board. Moreover, it should be emphasized that in 1935-1940, Nadir Davlet's parents also published a newspaper called the "National Flag" in the Far East. In this way he kept up his family's tradition.

We should note that in the last century China gave us two great historians. In the West of China, in 1934, Mirkasym Gusmanov was born, and 10 years later in 1944, Nadir Davlet was born in the East of China, in the city of Mukden. Although there was the Iron Curtain which prevented communication with the country of his ancestors, Nadir Davlet has made significant contributions to the study of humanities in Turkey like his predecessors Yusuf Akchura, Sadri Maksudi, Gabdelbari Battal, Akdas Nigmet Kurat and many other Tatar scholars. The distinguished scientist has a particular interest in Turkic world history and international relations. Nadir Davlet is the author of twenty

monographs published in different countries and his works are well-known and applied all over the world.

In Tatarstan, Nadir Davlet is well known as a great person and a prominent scientist. His four monographs and more than twenty scientific articles were published in Kazan. Not every expatriate, working in other countries gets such recognition. The research works of Nadir Davlet, translated into the Tatar language, have enriched our scientific concepts and have given an opportunity to see and evaluate historical events in new ways.

In 1998, Nadir Davlet's book "History of the Russian Turks' National Struggle" was translated into the Tatar language [1]. This work has been highly appreciated as the author analyses the national movement of the Volga-Ural region in the early 20th century basing on the Turkic peoples' history.

In 2005, the work of Nadir Davlet "What Happened to the Far Eastern Tatar-Bashkirs?" was published in the Tatar language; it describes the historical fate of Tatars who lived cohesively in the Far East in the 1920s-1940s [2]. This important historical issue has been studied by Larisa Usmanova, Rafael Adutov, and other historians. Being a representative of the Tatar emigration from this area, Nadir Davlet made specific observations, describing the bitter life of local Tatars in detail.

I would like to highlight Nadir Davlet's most significant work "The October Revolution of 1917 and the Turkish-Tatar National Assembly" published in 2008 by two publishing houses: "Assembly" and "National Book" in Kazan [3]. This historical issue had not been explored by our historians for political reasons and at that time it was the biggest step forward toward recovering our national statehood since 1552. In my opinion, the researcher had dedicated many years of his life to this theme as many thoughts about the National Assembly can be found in his previous works. Nadir Davlet analyses the opportunity to create the Volga-Urals state during the revolutionary period of 1917. The historian describes the circumstances of the development of the Tatar political movement, the Tatar nation undergoing various changes and renewals in the 20th century, the role of religious leaders, traders, entrepreneurs, and intellectuals, who were educated abroad in the Tatar national movement. He also explains his attitude toward evident weaknesses in the efforts to improve the national movement. For example, he noted that Tatars did not have enough forces and willpower to protect their rights and freedom. Nadir Davlet was right, believing that the creation of the nation's parliament, the National Assembly, under such conditions was a great achievement. Without the National Assembly and National Administrations, there would not have been TASSR, based on the Moscow decree. The emergence of the Republic of Tatarstan in 1920 was not just a gift from Moscow to the Tatar nation, as some current historians believe, but possibly one of the versions of the national liberation movement, the National Assembly, which was established by the Bolsheviks in the early 20th century.

Also, the historian gives his own explanation of the fact that the National Assembly was not able to continue its activity and the Tatar national movement eventually ceased to exist, or did not succeed. According to Nadir Davlet, the leaders of the national movement could not set clear common goals to the people and the opportunity to gain complete freedom was not taken seriously. The researcher concludes that the latter was the most crucial mistake made by the national movement. As I have mentioned earlier, this work, based on numerous historical sources written in different languages and coming from different countries, took a long time to write. Undoubtedly, we can call it the scholar's conceptual work.

As we know, the Revolution raised hopes among the Russian people, and too many sacrifices were made for the sake of national freedom. However, as the author is right to say, "however, quite a lot of political and life experience has been gained". Nadir Davlet has done invaluable work exploring this political experience and conveying it to the next generation. It is important for both scientists and politicians to rely on this experience in the future.

Nadir Davlet's fourth book has been translated into Tatar and was published in Kazan this year. This book is "Between the Nation and the Soviet Government. The October Revolution of 1917: Fighting for the Life of Russian Turks". The author continues the work he started long ago, expanding and deepening his own thoughts and ideas. The value of this scientific research consists in its analysis of the Russian Turk's national political movement (which is not only about Tatars, but also about people living in the Caucasus, Central Asia, and the Crimea) due to the changes and circumstances in Turkey's sociopolitical life, in other words it presents the Turkic view of the developments. In my opinion, his description and evaluation of the Muslim political movement in Russia is both interesting and meaningful.

Nadir Davlet also encourages his students to study Tatar history. Ismail Tyrkoglu is one of his students who works successfully in this area. This scientific school breeds bright professors. Ismail has a deep understanding of the relevant issues of Tatar scientific research, and following Mr. Davlet's tradition, he devotes one of his significant works to Gabderashit Ibrakhimov's activity.

To sum it up, I would like to quote Nadir Davlets's very timely and meaningful thought. In one of his works he makes the following observation: the Kazakh, Tatar, Turkish, and Uzbek languages are considered to be independent languages although they have all grown from one Turkic root. Russian and Serbian also have the same Slavic root as well as Albanian and Dutch which both originated from the German language. Still, representatives of the Turkic world can understand each other even if they speak their own mother tongue. And owing to dramatic changes in the Slavic or German languages, people who speak these languages do not understand each other. I believe that this observation is significant as understanding each other in the course of communication is of primary importance. This is a great achievement of the Turkish people and it is a reliable foundation for intercultural communication. This topical view sounds very true and shows the humanitarian capacities of the nation. The author has dedicated his life and research work to increasing mutual understanding among different people, enhancing intercultural communication, and promoting peace and harmony among peoples. We all wish Nadir Davlet good health and creative achievements.

**References**

1. *Däülät Nadir*. Russiya törkilärenеŋ milli köräsh tarikhy (1905-1907). Kazan: Milli kitap, 1998. 399b.
2. *Däülät Nadir*. Erak Könchygyshtagy tatar-bashkortlarga ni buldy. Kazan: Kazan däülät un-ty, 2005. 99b.
3. *Däülät Nadir*. 1917 Oktyabr' inkyylaby vä törk-tatar Milli Mäžlese: (Echke Rusiya vä Seber möselmannarynyŋMilli Mäžlese. 1917-1919). Kazan: Žyen: Milli kitap, 2008. 382b.

---

# КҮРЕНЕКЛЕ ТАРИХЧЫ НАДИР ДӘҮЛӘТ ЮБИЛЕЕ МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН

**Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан, Кремль ур., 18 нче йорт,
gilyzov1958@gmail.com.

Надир Дәүләт исемен мин беренче тапкыр 1980 еллар башында ишеттем. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзерге вакытта Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать) институтында эшләгән вакытта профессор Альфред Халиков яшь галимнәр өчен «Чит илләрдә татар галимнәре» дигән темага лекция укыган иде. Чыгыш миңа гаҗәеп тәэсир итте, таң калып тыңлап утырдым, чөнки чит илләрдәге шундый мәртәбәле, дан казанган татар зыялыларының тормышлары һәм эшчәнлекләре хакында ул вакытта әле артык күп белми идем… Шуннан бирле мин бу проблематика белән кызыксына башладым: татар эмиграциясе, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез язмышын өйрәнү бер зур фәнни юнәлешем булып китте. Шул вакыттан мин Надир Дәүләтне чын күңелдән ихтирам итәм, аның зур фәнни эшчәнлеге алдында баш иям.

Надир Дәүләт – уникаль, кабатланмас, гаҗәеп дәрәҗәдә үзенчәлекле һәм гыйбрәтле язмышлы шәхес. Ул үзенчәлекне, уникальлекне мин нәрсәдә күрәм соң?

Беренчесе – әлбәттә, Надир Дәүләтнең тормыш юлы. Аның катлаулы, борылмалы, фаҗигале дә, бәхетле дә үткәне миңа, гомумән, милләтебезнең язмышын хәтерләтә. Галимнең гаиләсе, бер яктан караганда, сугылган, куылган, туган ягын ташлап китәргә мәҗбүр булган, әмма, икенче яктан, шул авыр шартларда үзенең көчен, гайрәтен, горурлыгын һәм татарлыгын саклап кала алган.

Надир Дәүләт 1944 елның 15 июлендә Ерак Көнчыгышта, Мукден шәһәрендә туган. Бала чагыннан ук ул тормышның ачысын татыган: бик яшьли эти-әнисеннән аерылган, чит кулларда тәрбияләнгән. Язмыш аны ахыр чиктә Төркиягә алып килгән, 1967-1971 елларда Истанбул университетында белем алган.

Соңрак, 1972-1974 елларда, укуын Алманиядә, Мюнхендагы Людвиг Максимилиан университетында дәвам иткән. Яңадан Төркиягә әйләнеп кайткач, Надир Дәүләт бөтен күңелен үзе сайлаган тарихи мәсьәләләрне өйрәнүгә багышлый. Галим озак еллар Мәрмәрә университетында эшли, биредә төрки халыклар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәген җитәкли.

Шул ук вакытта Надир Дәүләтнең 1960-1970 елларда Төркиядә яшәүче милләтәшләребезнең милли үзаңын күтәрүдә, һәм бу илдә татар мәдәниятен пропагандалауда зур һәм нәтиҗәле ролен әйтеп узарга кирәк. Мәсәлән, Надир Дәүләтнең дә активлыгы һәм тырышлыгы белән, Тукай исемендәге яшьләр клубы, «Тукай бюллетене», ниһаять, 1960 еллар ахырында «Идел-Урал төрек татарларының ярдәмләшү» җәмгыяте оештырыла. Һичшиксез, бу изге гамәлләр – Кытайдан Төркиягә күчеп килгән яшь милләттәшләребез, шул исәптән Надир Дәүләтнең, фидакяр эшчәнлеге нәтиҗәсе. Бу урында шулай ук Төркиядә 1970 елларда күренекле эшкуар һәм меценат Әхмәт Вәли Мәнгәр ярдәме белән нәшер ителгән «Казан» журналын да атау урынлы булыр. Чит илләрдә, бигрәк тә Төркиядә яшәгән татар милләте вәкилләре язмышын тасвирлаган, һәм ун ел дәвамында басылып килгән бу журнал гаҗәеп бай эчтәлеге белән үзенә җәлеп итә. Минем карашымча, «Казан» журналы – сугыштан соң татарлар тарафыннан чит илләрдә басылган иң әһәмиятле һәм дәрәҗәле басма. Аны, бер дә шикләнмичә, сугышка кадәр Алманиядә Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә чыккан «Яңа милли юл» журналы белән бер рәткә куярга мөмкин. Шуны да искәртү урынлы булыр: 1970-1973 елларда Надир Дәүләт бу журналның баш мөхәррире булган, ә 1973-1980 елларда исә ул редколлегия әгъзасы вазифасын үтәгән. Сүз уңаеннан Надир Дәүләтнең әтисе белән әнисенең 1935-1945 елларда Ерак Көнчыгышта «Милли байрак» газетасын нәшер итүләрен ассызыкларга кирәк. Димәк, ул гаилә традициясенең дәвамчысы булып чыга.

Шунысы да игътибарга лаек: узган гасырда Кытай – безгә ике зур тарихчыны биргән ил. Көнбатыш Кытайда, Шәркый Төркестанда 1934 елда Миркасыйм Госманов дөньяга килгән булса, ун ел узуга, 1944 елда Кытайның Көнчыгышында Мукден шәһәрендә Надир әфәнде дөньяга аваз сала. Ата-бабалары иле белән аралашырга мөмкинлек бирмәгән тимер пәрдә булуга карамастан, ул, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Габделбарый Баттал, Әкъдәс Нигъмәт Курат һәм башка бик күп татар галимнәре кебек үк, Төркиядә гуманитар фәннәр үсешенә саллы өлеш керткән галим. Хөрмәтле галимебезне кызыксындырган төп фәнни мәсьәләләр: төрки дөнья тарихы һәм халыкара мөнәсәбәтләр. Надир Дәүләт – төрле телләрдә басылып чыккан 20 монография авторы, аның хезмәтләрен дөньяның төрле почмакларында беләләр, таныйлар һәм кулланалар.

Надир Дәүләтне Татарстанда, зур шәхес һәм олы галим буларак яхшы беләләр. Биредә аның 4 монографиясе һәм егермедән артык фәнни мәкаләсе дөнья күрде. Мондый бәхет чит илләрдә яшәп иҗат иткән милләттәшләребезнең бик азына гына елмайды. Тагын шул әһәмиятле: Надир Дәүләтнең татарчага тәрҗемә ителгән фәнни хезмәтләре безнең гыйльми карашларыбызны баетты, тарихи вакыйгаларны яңача күрергә һәм бәяләргә мөмкинлек бирде.

1998 елда Надир Дәүләтнең «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы» [1] китабы татар теленә тәрҗемә ителде. Бу хезмәт шунысы белән игътибарга лаек: автор XX йөз башында Идел-Урал төбәгендәге милли хәрәкәтне гомум төрки халыклар тарихы контекстында анализлый.

2005 елда инде Надир Дәүләтнең 1920-1940 елларда Ерак Шәрекъта күпләп һәм күмәкләшеп яшәгән татарларның тарихи язмышын тасвирлаган «Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды?» [2] хезмәте татар телендә дөнья күрде. Бу әһәмиятле тарихи мәсьәлә Лариса Усманова яки Рафаэль Адутов һ.б. тарихчылар тарафыннан өйрәнелде. Надир Дәүләт исә, шул төбәктә туып үскән татар эмиграциясе вәкиле буларак, үз сүзен әйтеп, бик тә үзенчәлекле күзәтүләр ясый, татарларның бу төбәктәге ачы язмышын тәфсилләп тасвирлый.

Надир Дәүләтнең Казанда 2008 елда «Җыен» һәм «Милли китап» нәшриятлары тарафыннан нәшер ителгән иң саллы «1917 ел октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милләт Мәҗлесе» [3] хезмәтен аерып күрсәтәсем килә. Безнең тарихчылар тарафыннан сәяси сәбәпләр аркасында тикшерелмичә килгән бу тарихи проблема – 1552 елдан соң милли дәүләтчелегебезне торгызу юнәлешендә ясалган иң зур адымнарның берсе. Галим, минем карашымча, бу хезмәтне язуга шактый озак гомерен багышлаган, чөнки аның моңа

кадәр басылган хезмәтләрендә Милли мәҗлес хакында фикерләр урын ала. Надир Дәүләт уйлануларының үзәгендә 1917 елгы революцион вакытта «Идел-Урал» дәүләтен төзү мөмкинлеген анализлау. Тарихчы татар сәяси хәрәкәте формалашуның алшартларын тирән тасвирлый, татар милләтенең XX йөз башында төрле яктан яңарыш кичерүен күрсәтә, татар милли хәрәкәтендә дин әһелләре, чит илләрдә белем алган зыялылар, сәүдәгәрләр һәм сәнагатьчеләрнең ролен ачыклый. Шул ук вакытта ул укучыларга милли хәрәкәт үсешендә күзәтелгән җитешсезлекләрне дә аңлата. Мәсәлән, татарлар арасында милләтне үз артыннан ияртеп барырлык көчләрнең азлыгы яисә гади халыкның үз ирекен яки хокукларын якларга психологик яктан әзерлексез булуы. Мондый шартларда татарлар тарафыннан милли парламент – Милләт мәҗлесе төзелү ул – милләтнең зур казанышы дип санавы белән Надир Дәүләт бик хаклы. Әгәр дә Милләт Мәҗлесе, Милли идарәләр булмаса, бәлки декрет нигезендә Мәскәүдән төшерелгән АССР да төзелмәгән булыр иде. 1920 елда Татарстан Республикасы төзелү – хәзерге вакытта аерым тарихчы галимнәр расларга тырышканча, татар халкына Мәскәү тарафыннан бирелгән бүләк түгел, бәлки XX йөз башы милли-азатлык хәрәкәтенең, Милли Мәҗлесләрнең большевиклар тарафыннан имгәтелеп тормышка ашырылган бер варианты.

Милләт мәҗлесе ни өчен үз эшчәнлеген дәвам итә алмаган, ни өчен татарларның милли хәрәкәте ахыр чиктә сүнгән яки уңышка ирешә алмаган дигән сорауларга да тарихчы үз аңлатмасын бирә. Надир Дәүләт фикеренчә, милли хәрәкәт җитәкчеләре халык алдында аңлаешлы бердәм максат куя алмаган, һәм шулай ук тулы бәйсезлек алу варианты да җитди кабул ителмәгән. Соңгысы милли хәрәкәтнең хәлиткеч хатасы булып тора дигән нәтиҗә ясый тарихчы. Бу хезмәт, төрле илләрдә сакланган төрле телләрдәге күпсанлы тарихи чыганаклар корпусына һәм махсус әдәбиятка нигезләнеп, алда әйтелгәнчә, озак еллар дәвамында язылган. Аны, һич шикләнмичә, тарихчы-галимнең концептуаль хезмәте дип атарга тулы нигез бар.

Революция, инкыйлаб дәвере, мәгълүм булганча, Русия халыкларында зур өметләр тудыра, милли азатлык көрәшендә бик күп корбаннар бирелә. Автор бик дөрес билгеләгәнчә,«шул ук вакытта байтак кына сәяси һәм хаяти тәҗрибә дә тупланмады түгел». Әнә шул сәяси тәҗрибәне өйрәнү һәм киләчәк буыннарга тапшыру юлында Надир Дәүләт тарафыннан биниһая зур эш башкарылды. Киләчәктә бу тәҗрибәгә таяну галимнәребез өчен генә түгел, сәясәтчеләребез өчен дә кирәкле гамәл булып тора.

Быел Казанда Надир Дәүләтнең татарчага тәрҗемә ителгән дүртенче китабы дөнья күрде. Ул «Милләт белән Совет арасында. 1917 елгы Октябрь инкыйлабы: Русия төркиләренең яшәеш өчен көрәше» дип атала. Тарихчы бу монографиясендә күптәннән башланган эшчәнлеген дәвам иткән, фикерләрен тагын да тирәнәйткән һәм киңәйткән. Русия төркиләренең милли-сәяси хәрәкәтен (биредә сүз татарлар турында гына түгел, ә Кавказ, Урта Азия, Кырым турында да бара), Төркиядә шул ук вакытта булган үзгәрешләр һәм хәлләр белән бәйләнештә анализлау, ягъни гомумтөрки караш беренче планга чыгу бу фәнни хезмәтнең төп яңалыгын билгели. Русиядәге мөселман сәяси хәрәкәтен мондый яссылыкта бәяләү шәхсән минем өчен бик тә кызыклы һәм әһәмиятле булып тоелды.

Надир Дәүләт татар тарихын тикшерүгә шәкертләрен дә актив җәлеп итә. Бу өлкәдә уңышлы эшләп килгән Исмаил Түркоглу – әнә шундыйларның берсе. Бу фәнни мәктәп чын профессионаллар әзерли. Исмаил бәй татар белеме фәне проблематикасын бик тирән аңлый, мәсәлән, аның Габдерәшит Ибраһимов эшчәнлегенә багышланган саллы хезмәте остазы Надир әфәнденең матур традициясен сыйфатлы дәрәҗәдә дәвам итә.

Мәкаләнең ахырында Надир Дәүләтнең бер бик тә актуаль һәм әһәмиятле фикерен китерәсем килә. Хезмәтләренең берсендә тарихчы шундый күзәтү ясый – казакъ, татар, төрек, үзбәк телләре инде күптәннән мөстәкыйль телләр булып санала, алар бер төрки тамырдан башланып киткәннәр. Рус һәм серб телләре дә бер славян тамырдан чыккан, яисә алман һәм һолланд теле бер герман теленнән башланган. Әмма төрки телләр вәкилләре бер-берсе белән үз телләрендә аралашсалар да аңлаша алалар. Ә славян яки герман телләре гасырлар дәвамында көчле үзгәрү сәбәпле, аларда сөйләшүчеләр бер-берсен аңламый. Бу күзәтүне мин аеруча әһәмиятле дип саныйм, чөнки халыкларның аралашуында иң әһәмиятлесе – бер-береңне аңлау. Бу – төрки халыкларның зур казанышы, һәм ул мәдәни бәйләнешләр үстерү өчен ышанычлы бер нигез булып тора. Бу караш

бүгенге көндә бик актуаль яңгырый һәм төрки халыкларның гуманитар потенциалының киңлеген күрсәтә. Надир Дәүләт гомерен һәм гыйльми эшчәнлеген төрле халыклар арасында аңлашуны арттыруга, мәдәни бағланышларны үстерүгә һәм халыкларның. бер-берсен хөрмәт итеп, дустанә яшәвен тәэмин итүгә багышлый. Без барыбыз да күренекле тарихчыга, хөрмәтле милләтәшебезгә сәламәтлек һәм зур иҗади уңышлар телибез.

**Әдәбият**


1. *Дәүләт Надир.* Руссия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905-1907). Казан: Милли китап, 1998. 399б.
2. *Дәүләт Надир.* Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. 99б.
3. *Дәүләт Надир.* 1917 Октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милли Мәҗлесе: (Эчке Русия вә Себер мөселманнарының Милли Мәҗлесе. 1917-1919). Казан: Җыен: Милли китап, 2008. 382б.